КАРАР

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керүче Кураз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 8 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» .2019 елның 4 октябрендәге 122 номерлы карарына таянып, 2022 елның 25 ноябрендә 13.00 сәг. узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. "2023 елда гражданнардан үзара салым җыюны Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Кураз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, I һәм II төркем инвалидларга, балигъ булмаган балалы гаиләләргә, көндезге уку рәвешендәге студентларга, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнарга әлеге түләүне 500 сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә сез ризамы дигән сорауга

1. вак таш сатып алу (илтеп җиткерү, тигезләү)
2. Кышкы чорда юлларны кардан чистарту
3. балалар мәйданчыгын киртәләү өчен материал сатып алуга;
4. Санитар саклау зонасында павильон урнаштыруга.”

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 54 граждан кертелде тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 38

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"!Әйе" 38 граждан тавыш бирде;

"Юк" 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Кураз авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләре дөрес дип санарга

2. "2023 елда гражданнардан үзара салым җыюны Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Песәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтәге кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, I һәм II төркем инвалидларга, балигъ булмаган балалы гаиләләргә, көндезге уку рәвешендәге студентларга, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнарга әлеге түләүне 500 сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә сез ризамы дигән сорауга карар кабул итәргә

1. вак таш сатып алу (илтеп җиткерү, тигезләү)
2. Кышкы чорда юлларны кардан чистарту
3. балалар мәйданчыгын киртәләү өчен материал сатып алуга;
4. Санитар саклау зонасында павильон урнаштыруга" - кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И. Мөхәммәтгалиев